**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Әлки муниципаль районы Юхмачы авыл җирлеге Советы**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Совет Юхмачинского сельского поселения Алькеевского муниципального района**

Адресы: 422885, ТР, Әлки районы, Юхмачы авылы, Ленин урамы ,1а
Тел./факс 8(84346) 74-224

Адрес:422885, РТ, Алькеевский район, с. Юхмачи, ул.Ленина, д.1а
тел./факс 8(84346) 74-224

РЕШЕНИЕ　　　　Юхмачы ав.　　　　КАРАР

2025 елның " 08 " августы　　　　№ 146

Әлки муниципаль районы Юхмачы авыл җирлеге Советының 23.10.2023 елның 83-нче номерылы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы " Юхмачы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставын раслау турында " карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (соңгы үзгәрешләре белән), «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Әлки районы Прокуратурасының хокук булдыру инициативасын өйрәнеп, муниципаль берәмлек Уставының 85,86 статьялары нигезендә «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Юхмачы авыл җирлеге Советы **карар кабул итте**:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының « Юхмачы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 23.10.2023 елның 83-нче карары белән (29.07.2024 елның 107-нче карары редакциясендә) 1 нче кушымта нигезендә расланган Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының « Юхмачы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2.Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.

3.«Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Юхмачы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.

4. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Юхмачы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карарны, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Юхмачы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы статьяларының яңа редакциясен дәүләт теркәвенә алганнан соң Юхмачы авыл җирлеге территориясендә: Татарстан Республикасы, Әлки районы, Юхмачы авылы, Ленин ур., 1а йортта махсус җиһазландырылган стендларда (бина җирле үзидарә), Школьная авылы, 8а йорт (авыл мәдәният йорты) һәм Әлки муниципаль районының рәсми сайттында (http://alkeevskiy tatarstan.ru.) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы
« Юхмачы авыл җирлеге»
Муниципаль берәмлек башлыгы,
Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы Ф.З.Нотфуллина

1 нче кушымта
Әлки муниципаль районы
Юхмачы авыл җирлеге
Советы карарына
08.08.2025 ел, № 146

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының " Юхмачы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

1. 5 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 19.1 пункт өстәргә:

"19.1" шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112 номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып барган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгеләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру".